**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
Глава
Какре-Елгинского
сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Кәкре-Елга авыл җирлеге
башлыгы

423320 с.Какре-Елга
ул.Советская, 22,
Тел. 37-0-49

Кэкре-Елга авылы, 423320
Совет урамы, 22,
Тел. 37-0-49

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «11» ноябрь 2019г. № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә;

2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар Җыенын уздыру вакыты-2019 елның 21 ноябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- Халык җыенын үткәрү урыны- Якты Юл авылы, Якты Юл урамы, 23 нче йорт;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 11 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган

материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Кәкре Елга авылы, Совет урамы, 22 йорты

- сайлау хокукына ия булган Якты Юл торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

-Якты Юл торак пункты халкына массаЮләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 400 сум куләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 200 сум Юләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Якты Юл бистәсендә су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү) ;

- Якты Юл бистәсендә юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);

- Якты Юл бистәсе территориясен җәйге вакытта чабып алу (килешү буенча эшләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

ӘЙЕ ЮК».

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга:Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Якты Юл авылы, Якты Юл, 15 йорт;

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык И.М.Мөхәмәтҗанов